**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__20____» ____03_____ 2019ел. № __62____

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 20 декабрендәге 207-29 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына» үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында ( 24.05.2013 ел №243-35 карары редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 20 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Сетевая компания» ААҖ тарафыннан Азнакай муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү турындагы тәкъдим белән бәйле рәвештә, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасы турында» гы 207-29 номерлы карары (24.05.2013 №243-35 карар редакциясендә) белән расланган Азнакай муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләүгә керешергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов